ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 декабрь 2025 ел № 10212

Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 19 октябрендәге 5649 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 19 октябрендәге 5649 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2023 елның 31 мартындагы 2594 номерлы, 2023 елның 25 августындагы 7763 номерлы, 2024 елның 5 апрелендәге 2211 номерлы, 2025 елның 7 маендагы 3320 номерлы, 2025 елның 22 августындагы 6177 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программа чараларын финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетында каралган акчалар хисабына 2023 елда – 30 567,40 мең сум, 2024 елда – 29 718,57 мең сум, 2025 елда – 34 665,19 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2023 (мең сум) | 2024 (мең сум) | 2025 (мең сум) | Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум) |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Муниципаль бюджет | 30 567,40 | 29 718,57 | 34 665,19 | 94 951,16 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | | - |
| | Барлыгы | 30 567,40 | 29 718,57 | 34 665,19 | 94 951,16»; |

- 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2023-2025 елларга Программаны финанслау күләме 94 951,16 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Программаны тормышка ашыру еллары буенча: 2023 ел – 30 567,40 мең сум, 2024 ел – 29 718,57 мең сум, 2025 ел – 34 665,19 мең сум.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.»;

- 8 бүлекне кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.Ә. Сәлимхановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 5 декабрендәге
10212 номерлы карарына
кушымта

8 бүлек. Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау

| Төп чараларның исеме | Башкаручы лар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| Максат: Яр Чаллы шәһәре территориясендә янгыннарны кисәтү буенча нәтиҗәле система булдыру | | | | | | | | | | |
| Бурыч: Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| «Янгын сүндерү-коткару отряды» МБУ материаль-техник тәэмин итү | Гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | 2023-2025 еллар | Алдан билгеләнгән бурычларны үтәүгә әзерлек дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 17 904,60 | 17 250,16 | 20 454,50 |
| Янгын куркынычсызлыгын ың беренчел чараларын үтәү | Мәгариф идарәсе | 2023-2025 еллар | Алдан билгеләнгән бурычларны үтәүгә әзерлек дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 11,05 | 33,61 | 33,60 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бурыч: шәһәрнең гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә, яшьләр сәясәте учреждениеләрендә, мәдәният учреждениеләрендә, физик культура һәм спорт учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Мәгариф идарәсе | 2023-2025 еллар | Авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 4 173,00 | 4 676,00 | 4 756,00 |
| Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Мәгариф идарәсе | 2023-2025 еллар | Авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 6 109,00 | 5 478,00 | 7 102,08 |
| Өстәмә белем бирү учреждениеләрендә | Мәгариф идарәсе | 2023-2025 еллар | Авариясез эксплуатация | 100 | 100 | 100 | 100 | 796,55 | 707,60 | 668,15 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | | | дәрәҗәсе, % | | | | | | | |
| Яшьләр сәясәте учреждениеләрендә автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Яшьләр белән эшләү идарәсе | 2023-2025 еллар | Авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 290,60 | 290,60 | 290,70 |
| Мәдәният учреждениеләрендә автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы | Мәдәният идарәсе | 2023-2025 еллар | Авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 407,40 | 407,40 | 519,71 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| комплексны адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| Физик культура һәм спорт учреждениеләрендә автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплексны адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Физик культура һәм спорт идарәсе | 2023-2025 еллар | Авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 875,20 | 875,20 | 840,45 |
| «Гомуми белем бирү оешмаларында укучылар арасында «Куркынычсызлык мәктәбе» республика слёт-ярышында катнашу | Мәгариф идарәсе | 2023-2025 еллар | Чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| Укучылар арасында янгынга каршы тематикага иң яхшы инша, иң яхшы рәсем һәм гамәли | Мәгариф идарәсе | 2023-2025 еллар | Чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| иҗат өлкәсендә иң яхшы эш конкурсында катнашу | | | | | | | | | | |
| барлыгы: | | | | | | | | 30 567,40 | 29 718,57 | 34 665,19 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева